БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
«15» 04 2026 ел

**КАРАР**
№ 158

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль учреждение хезмәткәрләренең хезмәт командировкаларына бәйле чыгымнарын каплау тәртибе һәм күләме турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә кунакханә хезмәтләре һәм урнаштыруның башка чаралары хезмәтләрен күрсәтү Кагыйдәләрен раслау турында» 2025 елның 27 ноябрендәге 1912 номерлы карары нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2019 елның 7 маендагы 183 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль учреждение хезмәткәрләренең хезмәт командировкаларына бәйле чыгымнарны каплау тәртибе һәм күләмнәре турындагы Нигезләмәгә (20.11.2024 ел, № 281 үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәреш кертергә:

- 5 пунктның 3 абзацында «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә кунакханә хезмәтләре күрсәтү Кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 18 ноябрендәге 1853 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясендә кунакханә хезмәтләре күрсәтү Кагыйдәләре белән» сүзләрен «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2025 елның 27 ноябрендәге 1912 номерлы карары белән расланган «Россия Федерациясендә кунакханә хезмәтләре һәм урнаштыруның башка чаралары хезмәтләрен күрсәтү Кагыйдәләре» сүзләренә алмаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгыма алам.

Җитәкче А.Ф.Хәйретдинов